КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 3 декабрь г.Казань № 1095

Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алуга түләү турында

Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтүне көчәйтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Өч яшькә кадәрге балалары булган, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган һәм мөлкәти тәэмин ителеш дәрәҗәсе «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына теркәлгән кушымта белән билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәти тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган гаиләләргә «Дару чаралары әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы Федераль законның 55 статьясындагы 7 өлеше белән күздә тотылган дару чараларын һәм башка даруханә ассортименты товарларын сатып алуга 5 мең сум күләмендә түләү (алга таба – дару чаралары сатып алуга түләү) билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Дару чаралары әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы Федераль законның 55 статьясындагы 7 өлеше белән күздә тотылган дару чаралары һәм башка даруханә ассортименты товарлары сатып алуга түләү бирү тәртибе турындагы нигезләмәне;

«Дару чаралары әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы Федераль законның 55 статьясындагы 7 өлеше белән күздә тотылган дару чаралары һәм башка даруханә ассортименты товарлары сатып алуга түләү бирү кысаларында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе белән кредит оешмалары арасында мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибен.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына гражданнарга дару чаралары сатып алуга түләү хисабыннан дару чаралары бирүгә вәкаләтле оешманы билгеләү буенча конкурс үткәрергә.

4. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенә бу карарны бастырып чыгарган көннән 10 көн эчендә «Республика Татарстан», «Ватаным Татарстан» газеталарында гамәлдәге законнар нигезендә кредит оешмалары белән бу карарны тормышка ашыру кысаларында үзара хезмәттәшлек итү турында килешү төзү хакында мәгълүмат урнаштырырга.

5. Бу карар белән раслана торган «Дару чаралары әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы Федераль законның 55 статьясындагы 7 өлеше белән күздә тотылган дару чаралары һәм башка даруханә ассортименты товарлары сатып алуга түләү бирү тәртибе турындагы нигезләмәне куллану буенча аңлатмалар бирү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Дару чаралары сатып алуга түләү турындагы мәгълүмат Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла. Әлеге мәгълүматны Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру (алу) «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

7. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетында карала торган финанс чаралары кысаларында дару чаралары сатып алуга түләү өчен кирәкле гамәли программа продуктын эшләүне тәэмин итәргә.

8. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

9. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 3 декабрь, 1095 нче
карары белән расланды

«Дару чаралары әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге
61-ФЗ номерлы Федераль законның 55 статьясындагы 7 өлеше белән
күздә тотылган дару чаралары һәм башка даруханә ассортименты
товарлары сатып алуга түләү бирү тәртибе турында
нигезләмә

1. Бу Нигезләмә өч яшькә кадәрге балалары булган, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган һәм мөлкәти тәэмин ителеш дәрәҗәсе «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына теркәлгән кушымта белән билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәти тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган гаиләләргә «Дару чаралары әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы Федераль законның 55 статьясындагы 7 өлеше белән күздә тотылган дару чаралары һәм башка даруханә ассортименты товарлары сатып алуга түләү (алга таба – дару чаралары сатып алуга түләү) бирү тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Дару чаралары сатып алуга түләү «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән гамәлгә куелган, 2020 елның 1 гыйнварыннан соң һәр туган, улыкка алынган, опекага алынган һәм аның белән бергә яшәү урыны буенча яки тору урыны буенча яшәгән өч яшькә кадәрге балага билгеләнгән балага айлык пособие алган ата-ананың (законлы вәкиленең) берсенә (алга таба – алучы) билгеләнә һәм алучының дару чаралары сатып алуга түләү алу максатларында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе белән үзара хезмәттәшлек турында килешү төзегән банкта яки башка кредит оешмасында ачылган блоклаштырылган максатчан шәхси счетларына (алга таба – блоклаштырылган максатчан шәхси счет) күчерелә.

3. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлегендә (алга таба – Үзәк бүлеге) блоклаштырылган максатчан шәхси счет реквизитлары булганда, дару чаралары сатып алуга түләү алучының яшәү урыны буенча Үзәк бүлеге тарафыннан автомат рәвештә, аның мөрәҗәгатеннән башка билгеләнә.

Үзәк бүлегендә блоклаштырылган максатчан шәхси счет реквизитлары булмаганда, дару чаралары сатып алуга түләү, блоклаштырылган максатчан шәхси счет балага айлык пособие бирү чорында ачылган булу шарты белән, блоклаштырылган максатчан шәхси счет ачылган көннән 10 эш көн эчендә алучыга автомат рәвештә, аның мөрәҗәгатеннән башка билгеләнә.

4. Дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү турында яки аны билгеләүдән баш тарту турында хәбәрнамә гариза бирүчегә Үзәк бүлеге тарафыннан аның балага айлык пособие билгеләү турындагы гаризасында күрсәтелгән ысул белән (язма рәвештә почта адресы буенча, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга СМС-хәбәр итеп) җиткерелә.

5. Дару чаралары сатып алуга түләү билгеләүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

балага өч яшь тулу;

балага айлык пособие бирү чоры тәмамланганнан соң блоклаштырылган максатчан шәхси счет ачу.

6. Дару чаралары сатып алуга түләү, дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү турында карар кабул ителгән айдан соң килүче айның 26 ысыннан да соңга калмыйча, балага айлык пособие бирү чоры эчендә бер тапкыр, әмма иң күбе елына ике тапкыр алучыларның блоклаштырылган максатчан шәхси счетларына күчереп гамәлгә ашырыла.

7. Алучының блоклаштырылган максатчан шәхси счетына күчерелгән дару чаралары сатып алуга түләү аның тарафыннан конкурс нигезендә сайлап алынган оешманың даруханә челтәрендә дару чаралары сатып алу өчен кулланыла.

8. Дару чаралары сатып алуга нигезсез алынган түләүне кире кайтару алучы тарафыннан ирекле рәвештә гамәлгә ашырыла, ә үз теләге белән кире кайтарудан баш тартылган очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә Үзәк бүлеге дәгъвасы буенча башкарыла.

9. Дару чаралары сатып алуга хокукы булган һәм аның вафат булуына бәйле рәвештә алынмый калган дару чаралары сатып алуга түләүнең исәпләнгән суммасы «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе тарафыннан Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә түләнә.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 3 декабрь, 1095 нче
карары белән расланды

«Дару чаралары әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге
61-ФЗ номерлы Федераль законның 55 статьясындагы 7 өлеше белән күздә тотылган дару чаралары һәм башка даруханә ассортименты товарлары сатып алуга түләү бирү кысаларында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе белән кредит оешмалары арасында мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибе

1. Бу Тәртип «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Үзәк) һәм өч яшькә кадәрге балалары булган, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күлә-меннән артмаган һәм мөлкәти тәэмин ителеш дәрәҗәсе «Татарстан Республика-сында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына теркәлгән кушымта белән билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәти тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган гаиләләргә «Дару чаралары әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы Федераль законның 55 статьясындагы 7 өлеше белән күздә тотылган дару чаралары һәм башка даруханә ассортименты товарлары сатып алуга түләүне (алга таба – дару чаралары сатып алуга түләү) гражданнарның блоклаштырылган максатчан шәхси счетларына дару чаралары сатып алуга түләү бирү кысаларында күчерү турында Үзәк белән килешү төзегән кредит оешмалары арасында мәгълүмати хезмәттәшлек процедурасын билгели.

2. Дару чаралары сатып алуга түләү бирү кысаларында үзара хезмәттәшлек Үзәк һәм кредит оешмалары арасында төзелгән мәгълүмати хезмәттәшлек турындагы килешүләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Кредит оешмалары көн саен блоклаштырылган максатчан шәхси счетлар ачкан гражданнарның электрон реестрын (алга таба – реестр) Үзәккә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән билгеләнгән файл форматында һәм структурасында җибәрә.

Реестрны тапшыру элемтәнең сакланган каналлары буенча электрон рәвештә гамәлгә ашырыла.

4. Үзәк ай саен алга таба гражданнарның блоклаштырылган максатчан шәхси счетларына кредит оешмалары тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек турында» 2005 ел, 22 гыйнвар, 20 нче карары белән күздә тотылган тәртиптә күчерү өчен дару чаралары сатып алуга түләү өчен билгеләнгән акчаны кредит оешмасына күчерә.

_______________________